# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

28 октябрь 2024 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, 24 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Суыксу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге Советының 28.10.2019 елның 164 № - лы карары белән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында», Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пунктында 2024 елның 25 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Сез Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пунктында 2023 елның 30 октябрендәге 4 номерлы җыенда кабул ителгән гражданнар акчаларын түбәндәге эш төрләрен башкаруга юнәлтеп, яңадан бүлүгә ризамы?:

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырту ремонтлау)
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторны тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, хезмәт хакы))
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау (янгын гидрантын урнаштыру өчен материаллар сатып алу).

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 80 катнашучы кертелгән, 42 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде: халык җыенында 42 катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге составына керүче Ташсу торак пунктында гражданнар җыены узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пунктында 2023 елның 30 октябрендәге 4 нче җыенда кабул ителгән гражданнарның акчаларын

түбәндәге эш төрләрен башкаруга юнәлтеп, яңадан бүлүгә ризамы дигән мәсьәлә буенча карарны таныргa:

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырту ремонтлау)
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторны тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, хезмәт хакы))
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау (янгын гидрантын урнаштыру өчен материаллар сатып алу).

«ӘЙЕ» «КАРШЫ» карарын таныргa.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Биектау муниципаль районы
Суыксу авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев